Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау торак пунктында
2020 елда үзара салым кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 нчы ноябрь 2019 нчы ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау торак пунктының халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Кзыл Тау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә кулланырга:

**Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Кзыл Тау торак пунктында урамнарны төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Кзыл Тау торак пунктында юлларны кардан чистарту.

**Территорияне төзекләндерү:**

--Кзыл Тау торак пункты өчен урам утлары сатып алу.

**Россия Федерациясе карары белән билгеләнгән вәкаләтләр чигендә җирлектә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-Кзыл Тау торак пунктының суэтем башнясы өчен насос сатып алу.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Дәүләтшин

СОВЕТ СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ